| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘТӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ | СОВЕТ АТЯСЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН |
|---|---|
| 423737, Әтәс авылы, Үзәк ур., 75, а йорты<br>e-mail:AktSik-Akt@yandex.ru | 423737, село Атясево, ул. Центральная, д. 75, а<br>e-mail:AktSik-Akt@yandex.ru |


**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«21» ноябрь 2024 ел № 6

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Актаныш муниципаль районының Әтәс авыл җирлегенең Чынык авылында узган гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 21 ноябрендә Әтәс авыл җирлегенең Чынык авылында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән "2025 елда үзара салымның бер тапкыр түләнә торган түләвен Җирлек чикләрендә теркәлгән 18 яшькә җиткән һәр гражданнан 500 (биш йөз) сум күләмендә, аларның яшәү урыны тавыш биргәндә үзләре күрсәткән Җыенда һәм мөнәсәбәтләрдә катнашуларына бәйсез рәвештә, 1 төркем инвалидлардан, сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучы гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашучылар) һәм аларның гаиләләре әгъзаларыннан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан (аларның саны җирлектә яшәүчеләрнең гомуми санының 30 процентыннан артмаска тиеш) һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым түләвен кертү фикерегез белән килешәсезме?»

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Чынык авылының урам юлларын карап тоту һәм ремонтлау);

- урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (Чынык авылын урам яктырту челтәрләрен тоту һәм ремонтлау);

«Әйе» 11
«Каршы» - 0
«Битараф»- 0;

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә: “Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 21 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 11. Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 11 граждан тавыш бирде;
"Каршы" позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.
"Битараф" позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнары җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Әтәс авыл Җирлегендә гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре дөрес.

Сорау буенча: - 2025 елда үзара салымның бер тапкыр түләвен 18 яшькә җиткән,

яшәү урыны Җирлек чикләрендә теркәлгән һәр гражданнан 500 (биш йөз) сум күләмендә, аларның тавыш биргәндә катнашуларына бәйсез рәвештә, җыенда катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, яшәү урынына теркәлгән һәр гражданнан, 1 төркем инвалидларыннан, сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучылардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашучылар) һәм аларның гаиләләре әгъзаларыннан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан аларның саны җирлектә яшәүчеләрнең гомуми санының 30 процентыннан артмаска тиеш), һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым түләвен кертү фикерегез белән килешәсезме?»:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Чынык авылының урам юлларын карап тоту һәм ремонтлау);

- урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (Чынык авылын урам яктырту челтәрләрен тоту һәм ремонтлау); карарын таныруга:

3. 3. Әлеге карарны Әтәс авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга — http://aktanysh.tatar.ru.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: А.М.Шәрипов